БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

9 октябрь 2020 ел № 15

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында аерым категориядәге затларга чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны тыю турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү сәбәпле, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. Балтач район Советының 2016 елның 28 апрелендәге 39 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында аерым категориядәге затларга чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны тыю турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.5 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Мирас алу нәтиҗәсендә Россия Федерациясе законнары яки чит дәүләт законнары нигезендә Нигезләмәнең 1.2 пунктында күрсәтелгән затлар тарафыннан Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетларга (кертемнәргә), акчаларга һәм кыйммәтле әйберләргә турыдан-туры һәм турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) ия булуга һәм (яки) чит ил финанс инструментларын файдалануга алган, шулай ук чит дәүләт законнары нигезендә гамәлгә куелган мирас мөлкәте (мирас фонды, траст) белән ышанычлы идарә итүне оештыручы һәм (яисә) бенефициар статусын алган очракта, күрсәтелгән затлар мирас алган яисә мирас мөлкәте (мирас фонды, траст) белән ышанычлы идарә итүне оештыручыга һәм (яисә) бенефициарга чит ил финанс инструментлары тапшырган көннән алып алты ай дәвамында Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетларны (кертемнәрне) ябарга, акчалар һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны туктатырга һәм (яисә) алынган чит ил финанс инструментларын аерып алуны гамәлгә ашырырга, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) файдалануны башка ысул белән туктатырга тиеш.»;

1.2. Нигезләмәнең 1.8 пунктында сүзтезмәдән соң, түбәндәге сүзтезмәне өстәргә «шулай ук чит ил финанс инструментларына инвестицияләүне күздә

тоткан һәм идарәне оештыручылары буларак әлеге затлар торган мөлкәт белән ышанычлы идарә итүне туктатырга.»;

1.3. Нигезләмәнең 2.8 пунктының 4 пунктчасындагы «чит дәүләтләрнең банкларына һәм башка оешмаларына» сүзтезмәсен төшереп калдырырга;

1.4. Нигезләмәнең 2.9 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Чит ил банкларына һәм башка чит ил оешмаларына, шулай ук чит дәүләтләрнең вәкаләтле органнарына гарызнамәләр, «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның 13.4 статьясының 1 өлешенең 3 пункты нигезендә тикшерүләр үткәрүгә бәйле гарызнамәләрдән тыш, Россия Федерациясе Прокуратурасы органнары тарафыннан Россия Федерациясе Генераль прокуроры билгели торган нигезләрдә һәм тәртиптә җибәрелә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы Башлыгы урынбасары Н.Н.Сабирҗановка йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р. Нотфуллин